ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОТУМБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Тумба ав. **КАРАР**

«10» апрель 2023 ел № 3

**Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмөшле лампаларны туплау урыны турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә кулланылучы һәм тиешле җыймау, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру аркасында гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү калдыклары белән эш итү Кагыйдәләре нигезендә, (алга таба - Кагыйдәләр) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кулланылган терегөмөшле лампаларны туплау урыннарын шул исәптән мондый туплану урыннарын оештыру Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә күпфатирлы йортларда туплану урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракта, әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Кулланучыларга туплану урыннары турында мәгълүмат бирү түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендлары аша башкарыла:

Татарстан Республиксы, Нурлат районы, Яңа Тумба ав, Шоссе ур., 4 й.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм httr://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш. http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы

Нурлат муниципаль районы

Яңа Тумба авыл җирлеге

башкарма комитеты җитәкчесе Л.Н. Осипов

Нурлат муниципаль районы

Яңа Тумба авыл җирлеге
башкарма комитетының 2023
елның 10 апрелендәге 3
номерлы карарына кушымта

**Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урыны**

| N п/п | Бина | Адресы |
|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы | Татарстан Республикасы, Нурлат районы,<br>Яңа Тумба ав,  Шоссе ур, 1й(тел.8(84345)4-72-16) |